# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең Багай торак пунктында**

**21 ноябрь, 2022 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 21 ноябрендә 10 сәгатьтә 00 минутта, 2022 елның 21 ноябрендә 13 сәгатьтә 00 минутта этаплап булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән «Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*
- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;
- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*
- су суырту башняларын, һәм сүукәргеч челтәрләрен карап тоту;
- су башняларын лицензияләү буенча әзерлек эшләре, тирә ягы койма белән тотып алу, һәм башка эшләр;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

*г) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:*
- янгын сүндерү ДЕПО карап тоту.»

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 115 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 76, бу 66 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 76 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең Багай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Багай авылы территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;
- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- су суырту башняларын, һәм суүкәргеч челтәрләрен карап тоту;
- су башняларын лицензияләү буенча әзерлек эшләре, тирә ягы койма белән тотып алу, һәм башка эшләр;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

*г) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:*

- янгын сүндерү ДЕПО карап тоту.»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Багай авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф.Кузнецова